КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 март г.Казань № 178

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 февраль, 55 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1367 нче, 2023 ел, 20 март, 296 нчы, 2023 ел, 11 июль, 810 нчы, 2024 ел, 20 май, 342 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

6.1 пунктта:

«г» пунктчасының беренче абзацында «(10 кеше)» сүзләрен «(11 кеше)» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җәмәгать тәртибен саклау һәм хәрәкәт иминлеген тәэмин итү бүлеге - өч кеше, шул исәптән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан - ике кеше (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән - бер кеше (килешү буенча);»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясе составында:

комиссия составыннан Д.Е.Будкинны, Я.О.Зайцевны, Е.А.Прытковны, М.Н.Хисаметдиновны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Смирнов Юрий Алексеевичны | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге башлыгы урынбасарын, комиссия секретарен |
| Гайнетдинов Булат Газинур улын | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының төбәкара элемтәләрне үстерү бүлеге башлыгын – матди байлыкларны эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме башлыгын |
| Нурмөхәммәтов Кәрим Альфред улын | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының автомобиль юллары идарәсе башлыгын – юл һәм транспорт белән тәэмин итү төркеме башлыгын |
| Тырышкин Сергей Анатольевичны | җәмәгать тәртибен саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлекне оештыру идарәсе башлыгы урынбасарын - урамнарда һәм массакүләм чаралар уздырганда җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгын (килешү буенча); |

Макаров Андрей Николаевич вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының икътисадый анализ һәм фаразлау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе - хәбәр итү һәм элемтә төркеме башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин